МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.11.2015 г.Казань № 251/2-пр

**ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының "2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы куллланучылар кооперациясен үстерү" ведомство максатчан программасын раслау турында" 2015 елның 21 октябрендәге 241/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә:

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының "2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү" ведомство максатчан программасын раслау турында" 2015 елның 21 октябрендәге 241/2-пр номерлы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын яхшыртуга грантлар бирү өчен авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) составыннан Ф.Ф. Рафыйковны чыгарырга;

конкурс комиссиясе составына Гомәров Таһир Илдар улын – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, крестьян-фермер хуҗалыкларын һәм кооперативларын үстерү секторының әйдәүче консультантын кертергә.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары Р.Р. Хәбиповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Министр М.Г. Әхмәтов

000149